Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

# Чаян



4

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АПРЕЛЬ * 2022 * КАЗАН

Сергей АНДРИАНОВ



Алмаз ХӘМЗИН

## БЕР ҖАЙ...

Сихри җаны бар Апрельнең,
Ничекме ул раслана?..
Унбер ай буе көттерә,
Тик шуннан соң башлана...

Күрми дә каласың аның
Кары эреп беткәнен.
Талчыбыклар бөреләнеп,
Яшелләнеп киткәнен.

Гөрләвекләр эз югалткан,
Чирәм башын калкыткан,
Кояш та иртә уянып,
Еш елмая офыктан.

Сыерчыклар өзеп сайрый,
Әллә мине күрүгә?..
Мәдхия җырлыйлар язга,
Яңа оя төбендә.

Артта калды беренче көн,
Алдалаштык шаярып.
Шаярышу үз арада,
Болай гына, кыланып.

Апрель килә өмет җыеп –
Хәлләр китәр җайланып...
Ләкин һаман гомер үтә,
Булачакка алданып.

Кешелектә чуалышлар,
Кануннарда буталыш.
Җайлап аккан елгаларның
Агымын кире борыш.

Җир байлыгын бүлешүләр,
Талау, сату, сугышлар...
Кемгә һаман нәрсә җитми –
Юкмыни соң сау башлар?

Юкмыни соң әүлияләр,
Кеше көен көйләргә?
Күпме чорлар, ничә еллар
Хәсрәт керә өйләргә.

Юкмыни соң әллә, Раббым,
Иплән язмыш корырга?
Нишләп соң Ул гел язалый
Эш кешесен тора да?..

Юкмыни соң шундый бер зат,
Халык хәлен аңларга?
Юктыр, юкса болай булмас
Бәлки алгы елларда?!

Бардыр бездә бары бер җай –
Менә шул Апрель бугай...
Чын хыялга чума күңел,
Шуннан аерма, Ходай!



Валерий ТАРАСЕНКО

## ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Иремнең хәтере бик начар. Бернәрсә дә исендә тормый: йә өйдә утны сүндерергә оныта, йә ирлек вазыйфасын үтәми – чүпне чыгарырга оныта... Ә күптән түгел туебызның көнен оныткан. Мин аннан бүләк көткән идем, бик кәефем кырылды, әлбәттә. Ләкин таныш психолог хатын: «Бу – нормаль хәл, – дип тынычландырды. – Галимнәр дә ирләрнең хәтере кыска, ә хатыннарныкы озын икәнен исбатлаганнар икән. Башыңнан чыгарып ташла!» – диде ул.

**Венера Г.**

КАЗАН

**– Галимнәр ничектер, ә мин моны күптән белә идем,** – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Әгәр ир кеше гафу иткән икән – ул оныта, ә хатын-кыз гафу итсә, гомер буе шуны исеңә төшереп тинтерәтәчәк...**

## ЯЗ КИЛЕР...


Ялкау мартның  салкын кояшында
Теләмичә генә кар эри.
Агач артларыннан карый-карый,
Басу-урманннарда яз йөри...

Йә җылы җил булып исеп куя,
Бөре булып бүртә ботакта,
Кошлар тавышы булып аваз бирә
Офык артындагы еракта.
Чишмә суы булып челтерәп ала
Бозга каткан агач улакта,
Ул тавышлар бергә кушылып яңгырый
Өмет җыры булып колакта...

Усал салкын күпме тырмашса да,
Вакыты аның калгандыр бик аз.
Бөдрә яшел толымнарын җәеп,
Килер туңган җиргә җылы яз...

**Ринат АБЗАЛОВ**

**Валерий ТАРАСЕНКО рәсемнәре**





# Билгесез юнәлештә

Гражданнарның тир түгеп җыйган акчаларын сакларга, ә кайчагында, тотрыксыз икътисадый хәлне истә тотып, арттырырга теләве табигый хәл. Шуңа күрә берәүләр шикәр белән карабодай җыя, икенчеләре күпләп көнкүреш техникасы ала, ә кемдер интернет биржаларында инвесторлык белән шөгыльләнергә маташа. Соңгыларын колач җәеп каршы алалар, әлбәттә. Алар өчен тәкъдимнәр Forex кәгазьләреннән дә күбрәк, ә процентлар күккә аша. Ничек тыелып каласың ди? Ләкин уңышлы инвестиция белән бәйле татлы өметләр еш кына чәлпәрәмә килә.

Инвестиция ялганы корбаннарының саны кимеми. Мәсәлән, Казанда бәхетен сынап карарга теләгән бер ханым акчаларын Mirlo-Inc брокерлык компаниясенә тапшырган. Ул, хәтта өлешчә кредитка да алып, фирмага 3,5 миллион сум илтеп биргән. Беренче вакытларда консультантлар аның белән даими элемтәдә булганнар. Аның белән бергә акчаның уңышлы эшләвенә шатланганнар һәм зур керемнәр турында хәбәр биреп торганнар. Ә шатлыгы эченә сыймаган ханым табышның өлешен алу турында сүз кузгаткач, шалтыратулар туктаган.

Тагын бер татарстанлы Profit Asist компаниясенең корбаны булган. Биржа белгечләренең осталыгына ул тулысынча ышанган, һәм шуңа күрә алар кулына үзенең 11 миллионын тапшырган. Белгечләрнең осталыгы чынлап та чиктән ашып торган, дөрес, башка өлкәдә. Финанс мөмкинлекләрен дәлилләү өчен аңа акчаны даими рәвештә күчереп торырга тәкъдим ясагач, аның күңелендә беренче тапкыр шик барлыкка килгән. Шуннан соң төп башында утырып калган "инвестор"ның брокерларны да, акчасын да күрмәгәнлеген сөйләп торуның кирәге юктыр.

Шул ук вакытта түбәнрәк керемле инвесторлар да "тиеннәрен" арттырудан баш тартмый. Биектауда яшәүче бер эшче ялган брокерларның банк карталарына тырышып-тырмашып җыйган ике миллионын күчергән. Ул нишләптер шулай итеп биржада акча эшләрмен дип уйлаган. Кама Тамагы районының Куйбышев исемендәге Затоннан инженер да шундый ук суммадан колак каккан. Ул, җуликлар тәкъдим иткән программаны файдаланып, акчасын шәхси кабинетына күчергән. Аннан алар, әлбәттә, билгесез юнәлештә "инвестицияләнгәннәр".

Узган ел эчендә генә йөздән артык "инвестор" хокук сак-лау органнарына мөрәҗәгать иткән. Кызганыч, бу югалган акчаларны кайтару, гомумән, мөмкин түгел. Алар инде күптән башка кешеләр файдасыны эшли. Чөнки, кагыйдә буларак, андый брокер компанияләре чит илдә теркәлгән була, безнең законнар анда эшләми, димәк, аларны җавапка тарту мөмкин түгел.

Ә тиз генә акча ясарга теләүчеләргә биржаларда чынлап эшләүче бай кешеләрне тыңлау артык булмас иде: биржа акча эшләүгә караганда аларны югалтырга мөмкинлекләрне күбрәк бирә. Монда хәтта мошенниклар да кирәк түгел.

**Людмила САФИУЛЛИНА**





Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Вячеслав ШИЛОВ




• • •

– Сездә юмор хисе ничек?

– Барын бар ул миндә. Ләкин ул олыгайган саен, оятсызлыкка әверелә бара.

• • •

– Карале, син шундый шәп кыз! Кемгәдер бәхет елмаячак бит...

– Бәлки сиңадыр?

– Нигә әле шундук миңа дисең?

• • •

Кичә "Конфискат" кибетенә кердем. Кытай базарындагы җыен чүп-чар шунда! Ә наркотиклар, алтыннар, валюта, коралфәлән кайда? Кая куялар аларны?

• • •

– Минем шигырьләремне элеккегә караганда хәзер икеләтә күбрәк кеше укый.

– Котлыйм, дускай! Мин синең өйләнгәнеңне ишетмәгән идем.

• • •

Сөяркә тотарга булдым әле. Киңәш бирегезче, нәрсә ашатырга икән аңа, саф һавада йөртү кирәкме һәм нинди прививкалар ясатырга?

• • •

Хатын-кызны көн саен тоткынлыкта бөтен хаҗәт-гозерен үтәп торуга караганда, аны яулап алу күпкә җиңелрәк.

• • •

Әгәр яхшылап уйлап карасаң, матрёшка белән бер шешә аракы арасында бернинди аерма юк. Беренчесен ачасың, аннан соң – икенчесе, өченчесе...

• • •

– Алло, бу психбольницамы?

– Әйе.

– Минем машинаны урладылар, каракны тотарга ярдәм итегез әле.

– Мондый эш белән без шөгыльләнмибез, полициягә шалтыратыгыз.

– Беләсезме, 1986 елгы «Запорожец» бит ул...

• • •

Кадрлар бүлегендә:

– Сез соңгы урында ничә ел эшләдегез?

– Ун ел.

– Мактауга лаек икәнсез. Ә ни өчен киттегез?

– Срогым тулды.

Абау!

## ГАДИ КЕШЕ КЕБЕК...

Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанда махсус хокук статусындагы 32 кешегә карата җинаять эше кузгатылган. Закон бозучылар арасында 22 муниципаль дәрәҗәдәге депутат, 4 адвокат, 2 җирлек башлыгы, 3 участок сайлау комиссиясе әгъзасы һәм бер судья. Соңгысы законсыз наркотиклар әйләнәшендә капкан.

## КӘГАЗЬДӘГЕ САРЫКЛАР

Питрәч районының башкарма комитететы башлыгы урынбасары Дамир Байгильдин ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгын төп башына утыртырга тырышып караган. Бу урынга килгәнче, түрә терлекче булып саналган. Ул министрлыкка барып, сарык үрчетү өчен грант алуга гариза биргән. Бу эшне башлап җибәрү максаты белән чиновник 1,4 миллион сум акча алган. Әмма бу суммага ул бернинди дә сарык алмаган, ә аның хезмәт кенәгәсендәге язмасы, әзерләгән отчётлары кебек үк, ялган булып чыккан. Хәзер элекке түрә суд карарын көтә.


## КАБЕР БИЗНЕСЫ

Чаллы муниципаль зираты башлыгына карата, аның "тыныч" эштә хезмәт куюына карамастан, өч статья буенча җинаять эше кузгатылган. Җан куйган әрвахларның туганнарын, шәхси эшмәкәрләр хезмәтеннән баш тартырга мәҗбүр итеп, югары бәяләр буенча үзе билгеләгән фирмалар белән генә килешенү төзеткән. Ә баш тартучыларга исә башлык үз зиратында кабер казырга рөхсәт бирмәгән.

## МИЛЛИОНЛЫ КОЛАЧ


Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясендә эшләүче ике ханым җиңел генә баеп китәргә булганнар. Хезмәт хакы исәпләү бүлеге башлыгы һәм баш бухгалтер ялган документлар әзерләп утырганнар. Программага бер сумма кертеп, алар вуз хезмәткәрләренә икенче, кимрәк акча түләгәннәр. Аермасын үз кесәләренә салганнар. Афера киң колачлы булып чыккан – дүрт ел эчендә үткен ханымнар 42 миллион сум үзләштергәннәр.

Вячеслав ШИЛОВ




Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Максим СМАГИН

## Нәни елмаюлар

### КИРЕСЕН ЭШЛИМ

Акыллы гына кеше булып саналган Вакыйф көтмәгәндә бер иләс-миләс хатынга өйләнеп куйды. Дуслары шаярта башлады:

– Нигә өйләндең син аңа? Акылсызрагын таба алмагансыңдыр инде.

Вакыйф аларга болай җавап бирде:

– Мин аннан ахмаклыклар ясамаска өйрәнәм. Әгәр җитди мәсьәләне хәл иткәндә җавап таба алмасам, хатыннан киңәш сорыйм, аны тыңлыйм да киресен эшлим. Һәм мәсьәлә дөрес хәл ителә.

### БИГРӘК ТӘМЛЕ БӘРӘҢГЕ!

Бер картның башка чыгып яшәүче уллары Гайфулла һәм Сәйфулланың саранлыкта тиңнәре булмаган. Хәлле генә яшәсәләр дә, әтиләре килгәндә аңа бәрәңгедән башка берни дә бирмиләр икән.

Берзаман әтиләре улларының икесен бергә туры китереп, болай диган:

– Сез, улларым, холыкларыгыз белән бер-берегезгә һич тә охшамагансыз. Менә Гайфуллага барсам, мине ничек кенә сыйламыйлар: пешкән бәрәңге дисеңме, май белән төелгәне дисеңме, кыздырган бәрәңге дисеңме – хан өстәле диярсең! Ә, Сәйфулла, сиңа барсам, бер үк нәрсә: бәрәңге дә бәрәңге...

Гайфулла, моны ишетеп, бик шатланган:

– Әти мине мактады бит!

Һәм әтисен төрле тәм-том белән сыйлый башлаган. Сәйфулла да Гайфулладан калырга теләмичә, әтисе алдына тәмле ризыклар куя башлаган.

### ТУЙ БҮЛӘГЕ

Ике дус, Самат белән Закир, өйләнергә булганнар. Берсе быел, ә икенчесе киләсе елга. Самат беренче булып өйләнгән. Закир аңа телевизор бүләк итәргә вәгъдә биргән. Ә бүләк юк та юк икән. Шулай итеп бер ел үтеп киткән.

Закирның өйләнер вакыты да җиткән. Самат туйда дустын болай котлаган:

– Дустымны өйләнүе белән котлыйм һәм аңа минем туема бүләк итмәгән телевизорыннан пульт бүләк итәм.

### САГЫНГАН

Нәфис район үзәгенә барган һәм иске танышына кунарга кергән. Хуҗа аны бик яхшы кабул иткән, ашатып-эчертеп йокларга яткырган. Ләкин бер төн урынына Нәфис кунакта өч төн уздырган. Хуҗа кунактан туярга өлгергән.

– Нәфис дус, өченче көнең китте бит инде. Хатының, балаларыңны сагынгансыңдыр инде? – дип сораган ул сак кына.

Тегесе:

– Чынлап та бераз сагындым бугай. Беләсеңме нәрсә? Машинаңа утыр да, аларны монда китер әле, – дип җавап биргән.








## ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Элек түләүле клиникада эшләгән табиб хәрби комиссариатка эшкә урнашкан. Бер атна үтүгә үк аны куып чыгарганнар – бөтен призывниклар да озак һәм кыйммәт дәвалану таләп итә торган авырулар булып чыккан.







• • •

Олы хирург яшенә күрсәтмә бирә:

– Шулай итеп, хезмәттәшем, бүген сезнең беренче мөстәкыйль операциягез. Бик игътибарлы булыгыз, югыйсә бармагыгызны кисәчәксез.

• • •

Онытма! Яхшы студент – яхшы табибка булачак. Ә начар студент – больница башлыгы булачак.

Антон МАКУНИ

## Юллама

Авыру бүлмәгә керү белән кушеткага сузылып ятты. Табиб аптыраган кыяфәт белән аңа карап катып калды.

– Сезне нәрсә борчый? – дип сорады ул аннан борчылып.

– Менә бу түшем, – диде авыру, бармагы белән йөрәге тирәсенә төртеп. – Доктор, сез миңа булышыгыз инде...

– Башта тикшеренергә кирәк бит, анализлар тапшырырга, кардиограмма ясатырга...

– Ясадылар инде, бернәрсә дә тапмадылар, – дип кулын селтәде авыру.

– Берни дәме?

– Берни дә.

– Бәлки нервыдандыр? Психиатрда булдыгызмы?

– Әле генә шуннан чыктым. Ул мине сезгә җибәрде...

– Мин бит хирург! – диде кызып китеп табиб. – Гафу итегез, мин кешеләрне ярам-кисәм, анысы да башка чара калмаганда!

– Беләм, беләм, ә мине коткарырга теләмисез инде алайса!

– Ничек коткарыйм ди, мин бит сезне бөтенләй белмим! Үзегез Ходай Тәгалә вәкиле – атакай булсагыз да... Кыскача гына булса да сөйләгез әле, ниндиерәк кеше сез?..

– Нәрсә сөйлим икән соң, – дип ухылдап куйды авыру. – Астыртын гына караштыргаладым, тыңлаштыргаладым, сагаладым, майладым, җайладым, урлаштыргаладым... Ә менә хәзер авырта... – һәм ул яңадан бармагы белән йөрәк тирәсенә төртте...

– Намусың бит бу! Сезне вөҗданыгыз борчый! Сезгә, атакай, гомумән, миңа түгел...

– Ә кемгә соң?

– Кемгә булсын, турыдан-туры Аллага!

– Ул булышырмы?

– Белмим, белмим, бик ялынып сорасагыз гына инде...

– Аңладым! – дип башын селкеде атакай һәм кыю гына кабинеттан чыгып китте.

Табиб, җиңел сулап, урындыгына утырды да маңгаеннан тирен сөртте. Шул вакытта кабинет ишеге яңадан ачылды һәм барлыкка килгән арадан әле генә чыгып киткән авыруның башы сузылды.

– Ну, нәрсә тагын? – диде ярсып доктор. – Мин бит сезгә барысын әйттем!

– Ул, – дип мышкылдады атакай, – карагыз әле, әйтмәссезме, кайсы кабинетта икән теге... сез әйткән... Алла кабул итә? Тагын, мөмкин булса, юллама язып бирегез әле шуңа... Үзегез беләсез бит, кәгазьсез беркая да кереп булмый хәзер... Ә иң әһәмиятлесе, – атакай, куркып, артына борылып карады да, пышылдап кына, – күпме акча тыгарга кирәк булыр икән кесәсенә кабул итәр өчен? – дип сорады.

# Шалтырату

Нури БУРНАШ

Телефоным шалтырады. Мобильник дисплеенда таныш булмаган номер килеп чыкты.

«Тагын “банк иминлеге хезмәте” жуликларыдыр инде, – дип уйлап куйдым мин. – Әллә берәр кирәкмәгән кыйммәтле товар рекламасымы? Йә тиз генә паспортсыз бирелә торган кредиттыр. Кыскасы, кая төртелсәң дә, ялган...”

Мин берникадәр вакыт таныш булмаган саннарга карап, кулымда телефонымны әйләндергәләдем. Җавап бирергә микән?

– Җавап бирә күрмә берүк, җүләр! – дип җикеренде эчке тавыш. – Күпме әйтергә була – мошенниклар бу!

– Кызы-ы-ык, кем исенә төшерде микән сине? – дип кызыксынды йомшак кына кирәкмәгәндә аваз сала торган кара җан. – Ә бәлки бу “ул”дыр? Телефон номерын алыштырган да, сиңа хәбәр салмакчы була. Кире кайтып, бөтенесен яңадан башларга тели торгандыр? Җавап бир тиз генә, егет бул...

– Юк, дускай, – диде каты итеп эчке тавыш. – Акылыңны җуйма, татлы хыялларыңны тирәнгә яшереп куй. Җүләр булма, ләм-мим!

– Ә шулай да, бәлки сөйләшеп карарга кирәктер? – дип тынмады кара җан. – Бәлки бу язмыш билгеседер? Кара аны, бәхетеңне кулыңнан ычкындыруың бар...

Нишләргә соң? Җавап бирергәме? Әллә таныш булмаган номерга төкерергәме? Кадалып киткере! Кызыксыну белән саклык арасындагы көрәш фикерләремне бутады.

Бәлки таңкә чөеп карарга кирәктер? Ал ягы төшсә – җавап бирәм, арт ягы булса – бирмим. Мобильник шалтыравын дәвам итте. Мин, кыюлыгымны җыеп, таңкәне чөйдем. Ул акрын гына, гүя үртәгән күк, ал ягы белән килеп төште. Менә ул – язмыш!

Мин тирән сулап алдым да телефонны колакка куйдым.

– Алло... Тыңлыйм сезне...

Трубкада шикләнергә урын калдырмый торган җитди тавыш ишетелде:

– Исәнмесез! Сезне АлдарБанкның иминлек хезмәте борчый. Әле генә сезнең счёттан акча күчерергә маташтылар...




Николай ВОРОНЦОВ

• • •

Ана кеше – укытучыга:

– Үтенәм сездән, улымның өй эшләрен киметегезче. Бик алҗыта, дәресләр белән төнгә кадәр утырырга туры килә.

– Улыгызны беркайчан да арыган кыяфәттә күргәнем юк, киресенчә, ул һәрвакыт көр һәм шат күңелле.

– Аның турында түгел, үзем белән ирем турында сөйлим...




Марат АБДЮШЕВ

Виктор ФЁДОРОВ




ИЛФАК

## ЗАМАНА БАЛАСЫ

Кыз бала әтисе янына килгән дә:

– Әти мин гашыйк булдым. Беләсеңме, ул Америкада яши.

– Ничек гашыйк булдың инде, кызым? – дип сораган әтисе.

– Менә кара. Без аның белән Мәңге кавышмам дигән интернет челтәрендә таныштык. Аннан соң ВКонтакте группасында дуслаштык, озак кына mail аша язышттык, ул миңа skype аша мәхәббәтен аңлатты һәм без инде ике ай whatsapp аша аралашып йөрибез. Кыскасы, әтием, син мине тәбрикли аласың!

Әтисе, бераз уйлап торгач:

– Әлбәттә. Тәбриклим. twitter аша "Әйе", дип җавап бир, Алиэкспресс интернет магазиныннан балалар сатып алырсыз, Paypal белән түләрсез. Ә инде туюың җитсә, eBay аша сатып җибәрерсең, кызым, яме... – дип җавап биргән әтисе.



Василий АЛЕКСАНДРОВ

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

## Яманламый булмый...

Дания һәр көн эштән кайтканда подъезд каршында күршесе Тәслимәне очрата. Ул шул йорт хатыннары белән эскәмиядә иркенләп утырып, сөйләшеп туймый. Билгеле инде, калганнары пенсиядәгеләр. Аларның өй эшләре беткән, балаларын карыйсы юк. Ә менә Тәслимә, әле пенсия яшенә дә җитмәгән, беркайда эшләми. Ни калган аңа шулар арасында?

Беркөн Дания үтеп китешли яннарында туктап калырга булды. Ни сөйләшкәннәрен тыңлыйсы килгәндер, күрәсең.

– Хәзерге заманда юньле ирләр бар микән? Әнә, минекен әйтсәк? Бер файдасы юк. Өйдә берни эшләми. Кайта да, сыра эчеп, диванда телевизор карап тик ята. – дип сөйләнә Тәслимәсе.

– И уңмадың инде иреңнән, уңмадың, – дип куәтләде аны бер күршесе.

– Карале, Тәслимә, синең ирең андый начар түгел бит. Эчеп йөргәне дә күренми. Сумка тотырып ризыклар да алып кайта, – диде икенчесе.

– Сумка тотырып сыра белән закуска алып кайта ул үзенә. Ә миңа балаларны ашатасы, йортны карыйсы бар.

– Бигрәк уңган да инде син, күрше. Кай арада өлгерәсең өй эшләрен эшләп, урамга чыгып, сәгатьләр буе монда утырырга?

– Арыгач, бераз ял итәсе дә килә бит.

Ерактан Тәслимәнең ире күренде.

– Әнә, кайтып килә инде. Хәзер тагын ашарга сорап, сыра эчеп ятачак. Ярый, мин дә керим. Йә монда тавыш чыгарып куяр.

Шулай диеп, Тәслимә өенә кереп китте. Аңа Дания да иярде. Икесе бер катта яшиләр, лифтта бергә менгәндә, Дания түзмәде:

– Тәслимә, нигә иреңне шулай яманлыйсың? Яхшы кеше бит ул. Өеңдә бер тавыш ишетелми. Балаларыгызның өсте бөтен, тамаклары тук.

– И-и, күрше, – дип җавап кайтарды Тәслимә, – Мин бит иртә кияүгә чыктым. Дөресен әйткәндә, ашарга да пешерә белмим. Шуңа күрә утырам инде урамда, ирем кайтканын көтеп. Менә ул кайта да, тәмле ризыклар пешереп, безне сыйлый. Син якын күрше булганга гына әйтәм – өйне дә ул җыештыра, балаларны да карый, Аллага шөкер!

– Шулай булгач, ник яманлыйсың соң иреңне? Аны мактарга кирәк! – дип аптырап калды Дания.

– Менә монысын син дөрес әйтмисең. Статистиканы кара. Илдә хатын-кызлар ирләргә караганда күбрәк. Ә безнең йортта ирсез хатыннар шыплап тулган. Мин иремне алар алдында мактап утырсам, ирсез калам бит. Ә болай, начар ир беркемгә дә кирәкми. Шуңа мин тыныч яшим.




Александр АЛЁШИН

Фәнзаман БАТТАЛ

## АҢЛАТЫРЛАР...

Туйдан соң ук үпкәләштек –
Йодрыклар китте хутка.
Бер генә тапкыр булса да,
"Аңлашып" кайттык судта.

Дуслык та юк, татулык та,
Төешәбез дөп тә дөп.
Ташлашабыз, кавышабыз –
Булмый һич тә төпләнеп.

Гауглалашып яшәсәк тә,
Балалар туа торды...
Ташлаттылар шул балалар
Талашлы "театрны".

Хәзер инде кыйнашмыйбыз –
Бер-беребезне сөябез:
Татулашып, бергәләшеп...
Балаларны төябез.

Тик шунысы, безгә карап,
Балалар да берләшә...
Гадәтләре хәтәр-харап –
Тәтелдәшеп әрләшә.

Күзләрендә усаллык бар,
Булсалар да кечкенә.
Кемнәр булып үсәр болар –
Аңлаҗ булмый һич кенә...




Александр ШУЛЬПИНОВ




## АЛТЫН ЧЫГАНАК

Мәскәүнең бер балалар бакчасында тәрбияче чын алтын чыганак тапкан. Өч яшьлек сабый бакчада тәреле алтын чылбырын югалткан. Ни уйларга белмәгән ана педагогтан шундый кыйммәтле әйбер тапмадыгызмы, дип сорауга, тискәре җавап алгач, ата-аналар чатында үз тарихы белән уртаклашкан. Бу төркемдә беренче генә югалу түгел икәне ачыклана. Эшкә полиция дә кушылган. Тәрбияче үзе балалардан чылбыр һәм тәреләрен салдырган, ул биш ел буе «Алтын табыш» белән шөгыльләнгән. Урланган әйберләрнең барысын да ломбардка илткән.

## ҖИНАЯТЬ ҺӘМ ҖӘЗА

Тамбов аэропортының полиция начальнигы Виталий Костяев җинаятьләрне ачканлыкны арттыру өчен үзе җинаять эшләткән. Җитәкчедән күрсәткечләр түбән булганга шелтә алганнан соң, ул бер ир-атны закон бозарга күндергән. «Җинаятьчегә» 6 патрон биргән, аны аэропорт терминалына алып барган һәм демонстратив рәвештә тоткарлаган. Ялганны шәхси куркынычсызлык хезмәткәрләре ачкан. Майорга уяу хезмәт иткән өчен рәхмәт сүзе түгел, ә реаль төрмә көтә.

## ЗЫЯНЛЫ БИЛГЕ

Свердловск тимер юлының Верещагино платформасыннан ерак түгел, укның дефекты аркасында, машинистлар өчен «куркыныч урын башы» дигән кисәтү билгесе куелган. Әмма беренче электричка ук куркыныч укка хәтле барып җитмәгән, состав кисәтүне бозган. Тиз генә куелган конструкция юлга артык якын куелган һәм барлык вагоннарны кырып чыккан. Башлангыч исәпләүләр буенча, электричка китерелгән зыян 3 млн. сумга бәяләнә.

## САФ ВӘХШИЛЕК

Одинцовода яшәүче этләр тотучы, кулындагы тешләнгән эзләрне күрсәтеп, полициягә мөрәҗәгать иткән. Әмма аны дүрт аяклы хайваннар түгел, ә шундый ук эт тотучы тешләгән. Ир-атлар этләре белән мәйданчыкта очрашканнар. Йонлачлар уенчыкларын бүлешә алмаганнар, һәм шуларның берсе яраткан эте өчен арага кергән. Икенче хуҗа да читтә калмаган. Нәтиҗәдә, ир-атларның берсе икенчесен кыйнаган һәм аның ике кулын да тешләгән. Этләр бу конфликтта катнашмаган.

Владимир ЯКОВЛЕВ




## ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Хатыннар бөтенесе дә яшь, тик кайберләре, башкаларына караганда, яшьрәк.

**Әгәр дә хатыннар бер ир өчен генә чибәрләнеп йөрсә, бу озакка сузылмас иде.**

Ир кешегә шатлык бирә торган никах — кызының кияүгә чыгуы.

**Юләр хатыннар чынлыкта алай ук юләр түгел, ә менә юләр ирләр – бөтенләй башка нәрсә.**

Мәхәббәттә бәхетле булыр өчен сукыр булу кирәкми: вакытывакыты белән күзләрне йомып тору да җитә.

**Хатын-кызның көче нәрсә әйтүендә түгел, ә аны ничә тапкыр әйтүендә.**

Өйләнүнең бер әйбәт ягы бар – дуслар теңкәгә тими башлый.

***(Сәю белгечләре мәҗлесендә язып алынды)***

Константин МАЛЬЦЕВ



Виктор ВЕСЕЛОВ

# Беркатлы ир

Кемгәдер елмая бит бәхет! Күптән түгел дус хатыным чүплектә чәшке тун тапкан. Размеры да туры килгән бит! Чүплек түгел, ә бутик диярсең! Бер атна да үтмәгәндер – чүп контейнерыннан өр-яңа айфон тартып чыгарган. Ире шуңа ышана икән...

Минем ирем дә искиткеч ышанучан. Өстәвенә, талымсыз – миннән нәрсә калган, шуны ашый. Нәкъ мәче кебек. Тик бер ягы бар – кыяр рассолы ярата. Эчүен үзе күп эчми болай – башына кайгы төшкәндә генә. Ә андый кайгылар – атна саен. Менә "Спартак" оттырган. Ә ул чын халык командасы бит. Халык менә шулай әчкечелеккә сабыша да инде... "Спартак"ка "Зенит җиде гол керткән. Дөнья беткән диярсең! Аның пеләш башында беренче ак бөртекләр барлыкка килгән. Мондый кайгыны тиз генә онытып булмый бит. Валерьянка эзли башлады. Әнинең ревматизмнан дәвалана торган даруын табып, төбенә кадәр эчеп бетергән. Ярый әле әни тыныч холыклы. Бер ай гына сүгенеп йөрде. Бөтен кияүләргә дә Ходай шундый кайгыртучан әби бирсен иде:

– Кияүкәем, муеныңа шарф бәйлә! Урамда бозлавык. Егылып, башың белән бәрелә күрмә! – Аның сеңлесе ритуаль фирмада эшли. Җирләү бик кыйммәткә төшә икән...

Ирем дә әбисен бик ярата. Туган көне җиткәндә, кызыксынып:

– Әни! Сезгә нәрсә бүләк итәргә икән?

– Аякка берәр җылы әйбер дә, колакка юньлерәк бер нәрсә инде.

– Була ул!

Һәм алдамады бит! Аяк табанына салырга җылы киез һәм колакны өшүдән саклый торган бөркәнчек бүләк ите.

Ирем бик шикчел. Бер-ике тапкыр ютәлләп, борынын тартып куя да: «Бәлки, ашыгыч ярдәм чакыртырбыз?!.» Мин аны берьюлы бөтен чирләрдән дәваладым. Ярып салдым: «Бәвел эчәчәксең. Башта әзләп кенә. Көненә берәр литр...»

Ул күзләрен акайтты: «Ул хәтле каян алыйм мин аны?!..»

– Ә мин нәрсәгә? Ярдәм итәрмен...

Ышанды һәм авырмый башлады. Бигрәк беркатлы инде. «Ирдә үз-үзенә ышаныч тәрбияләргә кирәк! – ди дус хатыным. – Иң мөһиме – чамасын белергә...» Ул әнә үзенең ирен шулкадәр тәрбияләгән ки, тегесе директорына киңәш бирүгә барып җиткән. Директоры планёркада сорау куйган: «Безнең унитазларны халык алмый. Нишләргә? Бәлки, чәчәкләр белән бизәргәдер?»

Ире торган да әйтеп салган: «Аларга су бачоклары кирәк».

Директор шунда ук аны эштән чыгарган. Урынын алырга тели дип уйлаган, ахры.

Әй, исемә төште: дус хатынга шалтыратырга кирәк. Кызыксынып алырга. Чүплектә тагын берәр нәрсә тапмады микән? Бәхете бар бит аның...




Игорь КИЙКО

# ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

«Чаян» журналы үзенең йөз еллык тарихы эчендә һәрвакыт дөнья күләмендә тынычлык өчен көрәште һәм армый-талмый сугыш чукмарларын хурлык баганасына терәде. Үткен каләм һәм пумала осталары төрле илләрдә нацистлар, империалистлар, колониалистлар һәм реваншистларны утлы табада биеттеләр. Аларның иң «яраткан» персонажы НАТО агрессив блогы һәм аларның иярченнәре булды. Ул елларның карикатураларына карасаң, аларның бүгенге көнгә дә туры килеп торуын күрәсең.

А. СТАНКЕВИЧ, 1961 ел.







И. ХАНТИМЕРОВ, 1966 ел.




И. ИЕНСЕН, 1961 ел.

И. БОБРОВИЦКИИ, 1962 ел.






КУКРЫНИКСЫ 1963 ел.



– Карагыз! Ул бит тынычлык өчен! Ә кулларын ул хәзер юар...

Э. ГЕЛЬМС, 1965 ел.



# Ә МИНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

Күрше хатыны сорый:

– Син, нәрсә, балаларыңны авылга илтеп куйдыңмыни?

– Әйе шул. Әти-әни янына буш кул белән кайтып керү әллә ничек...

• • •

Бухгалтер командировкадан кайткан хезмәткәрнең счётларын һәм квитанцияләрен тикшерә.

– Ә бу нинди коточкыч сумма?

– Кунакханә өчен.

– Ә сезгә аны кем сатып алырга кушты?

• • •

– Хатыннар, ирләргә караганда, озаграк яшиләр икән!

– Тол хатыннардыр ул...

• • •

– Тирә-ягыбызда шулхәтле камералы смартфоннар күп! Нигә соң НЛОлар турында яңа видеоязмалар юк?

– Мөгаен, кешеләр йолдызларны күзәтүдән бизгәннәрдер...

• • •

Шәһәрдәге карны җыештыру мәсьәләсенең нинди кыен хәлдә икәнен күрәсең дә, Рәсәй ни өчен җиңел генә Аляскадан баш тартканын һәм шатланып Кырымны кайтартканын аңлыйсың.

• • •

Тук ачның дусты түгел, ә эш бирүчесе!

• • •

Ә сез беләсезме, атаклы Норвегия чаңгычылары һәм биатлончылары ни өчен спорт карьералары бетү белән астмадан арыналар?

• • •

Кызык, бөтен күренекле кешеләр ни өчендер урам исемнәрен йөртәләр.

• • •

– Әти, мин вегетарианец булачакмын һәм ит ашаудан үсемлек белән туклану файдасына кучәм.

– Улым, нәрсә телисең шуны аша! Ләкин шуны онытма: хатын-кыздан ирләр файдасына ваз кичә күрмә.

Валерий ТАРАСЕНКО




Василий АЛЕКСАНДРОВ



Сергей ЕРМИЛОВ









## КҮРЕРГӘ ТЕЛӘМИЛӘР

Хөрмәтле редакция! Безнең Конституциянең иң төп матдәсендә белем алу хокукы тәфсилләп язылган. Каләм белән басылган законны кайчагында нәрсә белән тырнап бетерүне үзегез дә беләсез...

Мәсәлән, алыйк Чаллының сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен 75 нче һәм Түбән Каманың күрү сәләте чикләнгән балаларның 71 нче балалар бакчасы-мәктәбен. Монда инде күп еллар дәвамында укыр өчен ярак-лаштырылган махсус әсбапларны таба алмыйлар. Электрон дәреслекләр белән эш итү аларга зыян гына китерә – 15 минут эчендә балаларның күрү сәләте икеләтә кими. Шул сәбәпле, укытучылар дәреслекләрне яраклаштыру эшен үзләре үтәргә мәҗбүр булалар, 3–11 нче сыйныфларга китаптагы хәрефләрне зур итеп бастыралар. Мондый хәл бу мәктәпләрдә генә килеп тумаган, бөтен республика буенча шундый кыенлык. Күрәсең, әлеге мәсьәлә буенча җаваплылыкны бирәү дә тоймый, махсус китапларның федераль дәрәҗәдә дә юклыгын сәбәп итәләр. Әйтергә кирәк, күрше регионнарда мондый кыенлыктан чыгу хокукын бик яхшы кулланалар.

**Күрү сәләте чикләнгән балаларның әти-әниләре**

ЧАЛЛЫ, ТҮБӘН КАМА

## ИХТЫЯРНЫҢ КӨЧЕ ҖИТӘРМЕ?

Кадерле "Чаян"! Һич уйламассың, дөньяда җыен тузга язмаган ярышлар арасында менә мондые – иң куркыныч баскычлар ярышы да бар икәнне. Кайберләренә хәтта басып күтәрелергә дә ярамый, чөнки алар бик ышанычсыз чөнки. Менә без, Тынычлык бистәсендә яшәүчеләр, мондый баскычларның берсен – "Яшел Үзән" белән Столичная урамы тоташтыручысын шул ярыш исемлегенә кертергә әзер. Бертуктаусыз халык агымы аны шулхәтле куркыныч хәлгә китергән, хәтта тимер терәүләре дә тузган, ә бетон баскычлары кырылып беткән. Бу җайланма инде ике дистә ел буе ремонт дигән нәрсәне күрмәгән. Шәһәр хакимияте аны 2015 елда ук рәткә китерергә уйлаган иде, ләкин шуннан бирле әле бу тирәдә эш башларга маташкан бер генә кешенең дә күренгәне булмады. Бәлки безнең ихтыярыбыз әлеге баскычка җан һәм ямь кертер?..

**Э. ХӨСНУЛЛИН**

ЯШЕЛ ҮЗӘН

**Александр БРЮХАНОВ**

## МАХСУС ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Түшкәев ниндидер сәер хәлдә урам буйлап бара. Күңел нәрсәдер тели, ләкин нәрсә икәнен тәгаен үзе белми. Кинәт аның күз алдында язу пәйда булды – "Теләсә нинди теләкләрне үтибез". Ул башын күтәреп карады – "Хыял" чәчтарашханәсе. Кызыклы нәрсә бу. Кемнеңдер тормышта нәрсәдәр үзгәртү өчен бары тик чәчне алдырырга кирәк, дигән сүзләре исенә төште. Ләкин хәзер бит элекке парикмахерлар күптән юк, өчләтә акча каерырга торган стилистлар гына... Шулай да кызыксынып карарга булды. Ишекне ачып, башын тыкты...

Теге яктан шундук кемдер ишек белән аның башын кысты. Түшкәев кычкырырга дип авызын ачты, ләкин кинәт башына ак җәймә каплануын тойды, ә колак янында кайчы тавышы ишетелде.

Егерме минут чамасы узгач, ишек ачылды, ә аның җилкәсенә кемнеңдер авыр кулы төшеп кунды. Аның алдында зәңгәр күзле әзмәвер басып тора иде.... Ул чәч алдыруның бәясен атагач, Түшкәевкә кырып-себереп кесәсендә булган бөтен акчасын бирергә туры килде. Ирекә чыккач, ул як-ягына карана-карана юлын дәвам итте...

Урамның уң ягында ул югары бәяләре белән дан тоткан "Бирән тамак" кафесының ишегенә башы кысылган бер ирне абайлап алды. Ул да, кызыксынып, ишеккә башын тыккан булган, күрәсең. Ә хәзер аның авызына көчләп салат тутыралар һәм ниндидер сыекча салалар иде...

Аяк киемнәре кибетендә аягы ишеккә кысылган хатынны күреп алды. Ике кулында да сумка булгач, ишекне аягы белән ачмакчы булгандыр инде. Ә хәзер ул аякка өр-яңа күнитек кидереп маташалар...

– Гражданнарның керемнәре бәяләргә тәңгәл килмәгәч, менә нәрсә була бит... – дип уйлап куйды Түшкәев һәм ашыгып өе ягына юнәлде... Фатирының ишеге янына җиткәч, туктап калды. Ишекне ачаргамы, юкмы? Кем белә – анда да берәр нәрсәңне кыстырулары бар бит...



Вячеслав ШИЛОВ




Тәнзилә ДАВЫДОВА



• • •

Бер ир горурлык белән дуслары алдында мактана:

– Минем хатын җыр техникасын камилләштерү өчен бер елга чит илгә китә.

– Ай-һай, кыйммәткә төшә торгандыр инде бу

– Юк, безнең өчен бер тиенгә дә төшми. Кирәк кадәр акчаны шатланышып күршеләр җыеп бирде.

## Йолдыз ШӘРАПОВАГА – 60 яшь



• • •

60 кына әле аңа,
Ә үзе күптән туган...
Аның әле матур чагы,
Ай кебек, яңа туган!

Яшь-яшь шагыйрә әле ул,
Мәш килә балачакта.
Бер күрәм мәктәптә аны,
Шул көнне үк – детсадта.

Аның әле рәхәтләнеп
Язар чагы шигырьләр.
Уйларында кайный рифма,
Күңелендә – җор сүзләр...

60 кына әле аңа,
Әллә, бәлки, унсигез?..
Әсәрләрен укып баксаң –
Могҗиза: дәрья, диңгез!

Алмаз ХӘМЗИН

*Хөрмәтле укучыларыбыз! Юбилее уңаеннан даими авторыбыз Йолдыз Шәрапованың берничә иҗат җимешен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Һәм алга таба да журналыбыз битләрендә аның әсәрләрен укып, сөенергә язсын дигән теләктә калыйк.*

### ИРЕК ТӘМЕ

Әгәр уйлана башласаң
Нәрсә ул ирек диеп.
Йөреп кара көне буе
Кысан башмаклар киеп.

### АКЛАНМА

Кара булмасаң акланма,
Гаепләләр генә аклана.
Гаепсезләр акланганда,
Каралтучы шатлана.

### "ҮЗЕМ!"

Ах, бу үзем нинди татлы.
Үзәктә – гел "үзем".
И Ходаем, калганнарга
Бирә күрче түзем.

### БУЯУ

Караны да агарталар,
Ап-акны да каралталар.
Гайбәтчеләр нигә бүген
Оятны оныталар,
Буярга яраталар.

Авызыңны ачып йөрсәң,
Әгәр булмасаң уяу.
Җаныңа яра уярлар,
Сиңа да сылап куярлар –
Телләрендә күп буяу.

• • •

Сата-ала белми идек,
Инде өйрәндек.
Бик остаргач, намусны да
Сатып җибәрдек...

• • •

Яралый сүзләрең –
Дәвалый күзләрең.
Яраланып-дәваланып
Яшим. Түзәмен.

### «САЕСКАН КИЛӘ»

Безнең Буа районына Фәезханов дигән яңа райком секретарен билгеләгәч була бу хәл. Яңа җитәкченең колхозларга, фермаларга, әйтеп-нитеп тормый, капыл гына килеп төшү гадәте бар икән. Ләкин колхоз рәисләре төрле чыганаклардан бу хакта алдан белеп, итәк-чабуларын җыеп калырга ашыгалар. Башлык киләсен белгән бер рәис ферма тәрәзәләрен юарга авылның бөтен карчыкларын чакыра. Әбиләр ак яулыкларын җилфердәтеп, урындыкларга менеп басып, юа-җыя башлыйлар. Шул вакытта ишек ачыла да аннан... район башлыгы килеп керә һәм бик нык гаҗәпләнеп:

– Әби, анда ник мендең, ни эшлисең? – дип сорый.

– Әй улым, – ди әби, зарын тыңларга кеше табылуына сөенеп, – саескан килә диләр бит, җыярга куштылар...

Билгеле инде, башлык башлы була, үзе турында сүз барганны тиз аңлап ала. Елмая да:

– Төш әби, җаным, төш, ул саескан мин! – ди.

Өйләр җыештырып, урындыкка менеп баскан кешедән безнең якларда әле хәзер дә: "Саескан киләме әллә?" – дип шаяртып сорыйлар.

### АТЛАР КЕБЕК

Тугарырга янәшәдә
Атлар калмагач,
Үзебез тугарылдык та
Калдык ялангач.
Әдәп юклык күрегез сез
Менә нишләтә.
Сәхнәләргә мендерә дә
Аттай кешнәтә.



# Хәзер җырлар ничек туа

Ишек шакымый гына бүлмәгә бәрәү керде.

– Мин композитор. Синең янга килдем. Яңа җыр яздым. Оркестрың белән шуны радиодан яңгыратырга, телевидениедән күрсәтергә, соңыннан интернатка куярга иде, – диде.

– Интернеткадыр, – дип төзәттем мин аны.

– Әйе, әйе.

– Нотасын бир, – дидем мин дә, "син"гә күчеп.

– Нотасы юк, нота танымыйм, – ди бу.

Миңа кызык булып китте: үзе композитор, ә нота яза белми. Шофёр булып эшли – машина йөртә белмәгән кебек була түгелме соң инде?

– Элек нотаны яхшы танышым язып бирә иде...

– Алайса, җырла, ә мин нотага төшерәм.

– Лә-лә-лә, лә-лә-лә... – дип шыңшыды, түзеп тыңлап утырдым. Ни моңы, ни көе дигәндәй... Җырга бит интонацияләр, кульминацияләр һәм башка компонентлар кирәк. Ә моның бернәрсәсе дә юк. Көе дә җырлаган саен, гел үзгәреп тора. Ничек итсәм иттем, шул «лә-лә»ләрдән күңелгә ятышлы бер нәрсә ясадым. "Композитор"ның үтенече буенча оркестрга да язарга кирәк бит әле. Әй аның эше, мәшәкате, четереклелеге. Акылың белән сабырлыгың гына җитсен!

Башта баян өчен клавир яздым, аннан соң шушы клавирны файдаланып – партитура, ә партитурадан соң башкаручыга партияләр өләшеп чыктым.

Төгәлрәк әйткәндә, иҗат баскычлары болай булды: көйгә баслар уйлап таптым, шуларга аккордлар (гармония) яздым, аннары җырның сүзләрен ноталар астына туры китердем. Темп, характер, динамика (тавышның көчлелеге) мәсьәләләрен хәл иттем, эчтәлегенә карап күп нәрсәне күз уңында тоттым.

Клавирдан 60 кешелек оркестр өчен партитура яздым. Подголосоклар (өстәмә тавышлар, орган пунктлары һәм башкалар) өстәдем. Бернichә репетиция ясап, әсәр килешле рәвешкә керде.

Китерелгән җыр текстларының башы юк, кушымтасы гына бар. Анысы да куанырлык түгел, төзәткәләп язгач, болайрак булып чыкты.

*Туган авылым Куакбаш,*
*Куакбаш, Куакбаш.*
*Беткән авыллар бик күп,*
*Ә син исән, Куакбаш!*

– Ә кемгә җырлатасың? – дим.

– Илсурга...

– Кайсысына?

– Озынына.

– Аңлашылды...

Репетицияләр озак һәм нәтиҗәле килеп чыкты. Җыр халыкка таралды. Радиодан яңгыраттылар, телевизордан күрсәттеләр, интернетка куйдылар. "Композитор" дип аталганы да, җырчысы да умырып акча алгандыр. Ә мине, "лә-лә-лә"дән дөньякүләм әһәмияткә ия булган классик әсәр тудыручыны, искә алучы да булмады.

Бу җыр радиодан еш тапшырыла. Композиторын да игълан итәләр – Нотабелмәс Бикталантович Ләләмин. Ә мин беркем түгел. Менә күп җырлар хәзер ничек туа!..

*Яфракларым минем нинди эре,*
*Яшеллегем, – диде, – мул да соң!*
*Мул яфракны колмак ярган иде,*
*Ә мактадлы колмак колгасы.*

**Кирам САТИЕВ,**
**Татарстанның халык артисты.**




**Ринат АБЗАЛОВ**



**САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ**

1923 елдан чыга.

**№ 4 (1917) апрель 2022**

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

**Язылу индекслары:**
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 30.03.2022 ел.
Тираж – 2742 Заказ О-0895

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

# Уйна да, уйла да!

ШАГЫЙРӘ ШӘМСИЯ ...
...-МИМЕШ

КОМПОЗИТОР ... ШӘМСЕТДИНОВ

ОЗЫНЛЫК БЕРӘМЛЕГЕ
"ТӘРӘЗӘ ТӨБЕМ ИСЛЕ ..."
"... ЕМНЕ ӨЗМӘ ГЕНӘ"
КУРКУ

НОТА
"...ГЫНДА ТУЛГАН АЙ ГЫНА"

ЛОТЕРЕЯДА ...(-2)
ШАХМАТ ФИГУРАСЫ

ЖАННА Д'...
ӘЙТКӘН СҮЗ

"...— САРЫ САГЫШ"
РӘССАМ МӘХМҮТ ...

"ЖИДЕГӘН ЧИШМӘЛӘРДӘ ЖИДЕ ..."

ЖЫРЧЫ АЙДАР ...

НОТА
ВЯТКА
"...МА, ВАКЫТ"

"ҺАВАЛАРДА ОЧА ИКЕ ...КОШ"

"...." ФИКЕР
"АЙ, ... БУЙЛАРЫ"

"ГҮЗӘЛЕМ МИНЕМ, ...!"

(-1)...-ШӨҺРӘТ

ЮВЕЛИР ЭШЛӘРЕНДӘ ҮЛЧӘҮ БЕРӘМЛЕГЕ

ЖИҢ ТӨРЕ

КИНОАКТЁР БРЮС ...

"... БУЙЛАРЫ"
"... КИЛӘ АВТОМОБИЛЬ"

100 м²

"... КАЗАН АРТЫНДА"
ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА

"... ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ"

КОЛ ...

ЖЫРЧЫ, ГАРМУНЧЫ ФӘН ...
"... ТРАГЕДИЯСЕ"

МОСТАФА ...

ФАСИЛ ...

КОСМОС

"... КҮҢЕЛЛЕ БУЛУЫННЫҢ СЕРЕН ӘЙТ, ДИЛӘР"

АНТОНОВ САМОЛЁТЫ

"ИДЕЛ БУЕ — ИМИН ..."

1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12

Ринат АБЗАЛОВ төзеде




1. Кешене эш нинди кимчелекләрдән коткара?
2. Янәшәләп машина куюда иң ачуны китергәне нәрсә?
3. Нәрсә ул туй?
4. Себер турында иң төгәл мәгълүматны ничек алырга була?
5. Хатыныңның энисе сине "улым" дип атый башлавы нәрсәне аңлата?
6. Нәрсә ул никах?
7. Эчкече кем ул (алкаш)?

## ҖАВАПЛАР

1. Моңсулыктан, бозыклыктан, мохтаҗлыктан һәм пенсия индексациясеннән. 2. Шаһитлар. 3. Бөтенесе ачыклана торган мизгел. 4. Искәрмә (ссылка) белән файдаланып. 5. Яз җиткән, ә бакчадагы эш – муеннан. 6. Ике кешенең талашызгышуыннан соң, еш кына була торган тыныч кына яшәп алу мизгеле. 7. Һәрвакыт кәгазь акча белән генә сатып алучы.

**Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.**

**Ч**аянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 3 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«КАРЛАР ЯВА ТЫН ГЫНА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
**Ф. ГАЙНЕТДИНОВ** (Башкортстан, Балтач р-ны, Иске Тимкә ав.),
**В. ПЕТРОВ** (Минзәлә р-ны, Кадрәк ав.),
**С. ШӘЙХУЛЛИН** (Казан).

Җиңүчебез – Кадрәктән
**Владимир ПЕТРОВ!**

## Айдар ҮТӘГӘНОВ



Казан рәссамы Айдар Үтәгәнов Мәскәү полиграфия институтын тәмамлагач, «Азат хатын», «Ялкын», «Салават күпере» журналларында баш рәссам булып эшли.

Һәм иҗади тормышының дәверендә ул «Чаян» белән хезмәттәшлек итә, оста сатира графигы булып таныла. Айдарның беренче карикатурасы журналда 1961 елда, ул әле җиденче сыйныф укучысы буларак, басылып чыга. Бу вернисаж рәссамның тууына 75 ел уңаеннан багышлана.







